| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» 07 2026 ел № 213

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын яңа уку елына кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, мәгариф оешмаларын яңа уку елына оешкан төстә һәм үз вакытында әзерләү, белем бирү хезмәтләренең сыйфатын күтәрү, аларның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын яңа уку елына кабул итү буенча район комиссиясе турындагы Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын уку елына кабул итү буенча комиссияне 2 нче кушымта нигезендә төзергә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмаларының яңа уку елына әзерлеген бәяләү турындагы Нигезләмәне 3 нче кушымта нигезендә расларга.

4. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ га түбәндәге бурычларны йөкләргә:

- учреждениеләрнең яңа уку елына әзерлеген тикшерү өчен Акт формасын әзерләргә;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмаларының яңа уку елына әзерлеген кабул итү графигын төзергә;

- комиссия эше өчен шартлар тудырырга;

- муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын кабул итү нәтиҗәләрен әзерләргә.

5. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына мәгариф оешмаларын кабул итүне оештыру өчен бюджеттан акча бүлеп бирергә.

6. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын уку елына кабул итү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 22июлендәге 236 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

7. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын 2019-2020 уку елына кабул итү турында» 2019 елның 2 июлендәге 248 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «04» 07
213 номерлы карарына
1 нче кушымта

Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын яңа уку елына кабул итү комиссиясе турында Нигезләмә

Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын оператив рәвештә яңа уку елына әзерләү, муниципаль бюджет мәгариф оешмаларында гомуми белем бирү программаларын уңышлы гамәлгә ашыруга, балаларның гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән тиешле санитария-гигиена таләпләренә, янгынга каршы куркынычсызлык таләпләренә туры килә торган шартлар тудыру максатларында эшләнде.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын яңа уку елына кабул итү комиссиясе (алга таба - Комиссия) белем бирү оешмаларының матди-техник дәрәҗәсен тиешле дәрәҗәдә тотуга, укыту-тәрбия процессын тәэмин итүгә, РФ гражданнарының белем алуга конституцион хокукларын гамәлгә ашыруга, санитар гигиена, янгын куркынычсызлыгы нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәүгә, укучыларның һәм хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән бердәм дәүләт сәясәтен формалаштыру һәм координацияләү буенча коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.2. Муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын уку елына кабул итү комиссиясе турында әлеге нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) комиссия тарафыннан районның муниципаль бюджет мәгариф оешмаларының уку елына әзерлеген тикшерү тәртибен билгели.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә белем бирү турында» Россия Федерациясе Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдимнәренә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм боерыкларына, Дәүләт янгын күзәтчелегенең норматив-хокукый актларына һәм башка ведомстволарның актларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

II. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Матди-техник базаны саклау һәм үстерү, балаларны укыту,

тәрбияләү һәм педагогик һәм техник персоналның эшләве өчен уңайлы, имин шартлар булдыруның нигезле стратегиясен билгеләү.

2.2. Районның белем бирү оешмаларын карап тоту, үстерү, аларда укутәрбия процессын тәэмин итү, балаларның һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлеген һәм тормышын саклау өчен шартлар булдыру мәсьәләсен хәл итүдә катнашу.

2.3. Мәгариф оешмаларының матди-техник базасын тикшерү:

- мәгариф оешмалары базасының (биналар, корылмалар, җиһазлар) янгын һәм техник куркынычсызлык таләпләренә, СанПиН таләпләренә туры килүе, күрсәтмәләрне үтәү;

- укыту-тәрбия процессы өчен шартлар, физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү, хезмәткә өйрәтү, тәрбияләү өчен шартлар булдыру;

- балаларның туклануын оештыру, технологик һәм суыткыч җиһазларның торышы;

- балаларның һәм хезмәткәрләрнең җәрәхәтләнүен булдырмау өчен шартлар тудыру;

- укучыларның сәламәтлегенә медицина хезмәте күрсәтү һәм күзәтү өчен шартлар булдыру;

- район мәгариф идарәсенә белем бирү оешмаларының яңа уку елына әзерлеге турында актларны әзерләп тапшыру.

## III. Комиссия эшчәнлеген оештыру

3.1. Комиссия утырышлары ихтыяҗ булганда үткәрелә.

3.2. Комиссиянең мәгариф оешмаларына чыгуы махсус график буенча башкарыла. Мәгариф оешмасы кабул итүгә әзер булмаган очракта, комиссиянең чыгуы соңрак срокта кабат үткәрелергә мөмкин.

3.3. Комиссия карарлары тәкъдим итү характерында.

3.4. Чыгуларны рәис яки аның урынбасары алып бара, сәркатип утырышларны протоколлаштыра.

3.5. Комиссия белем бирү оешмаларын кабул итү актларын раслый.

## IV. Комиссия әгъзаларының хокуклары

4.1. Оешманың уку, хезмәт һәм көнкүреш биналарына тоткарлыксыз керү һәм карау.

4.2. Мәгариф оешмалары җитәкчеләреннән үз компетенциясе кысаларында кирәкле белешмәләр, мәгълүмат, документлар соратып алу.

4.3. Комиссия утырышына хокук бозуларны төзәтү буенча тәкъдимнәр кертү һәм срокларны билгеләү.

## V. Комиссия формалаштыру

5.1. Комиссиянең структурасы һәм составы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «04» 07
213 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын яңа уку елына кабул итү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | Гайнетдинов И. Ф., Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) |
| Комиссия рәисе урынбасары: | Мөхәрләмов Р.К., «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Комиссия секретаре: | Нуриева Г.Ф., «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ методисты |
| Комиссия әгъзалары: | Сәгъдиев И. Н., Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| | Гарипова Э.Ф., Балтач муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе |
| | Абдрахманова Р.Р., Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы урынбасары |
| | Бариева А.Х.,Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ методисты |
| | Түбәндәге бүлек вәкилләре килешү буенча:<br>Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенең Арча һәм Биектау районнарындагы территориаль бүлеге; |
| | җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция |

бүлеге;

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эше идарәсе Кукмара һәм Балтач муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлеге;

Балтач муниципаль районының «Хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУ

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «04» 07
213 номерлы карарына
3 нче кушымта

Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмаларының
яңа уку елына әзерлеген бәяләү турында
Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү оешмаларының яңа уку елына әзерлеген бәяләү турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль Законга туры китереп эшләнде.

1.2. Белем бирү оешмаларын кабул итү комиссия тарафыннан башкарыла, аның составына килешү буенча түбәндәгеләр керә:

- рәис - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты житәкчесе урынбасары;
- рәис урынбасары - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак - коммуналь хуҗалык бүлеге вәкилләре;
- һөнәри иҗтимагый оешма һәм берләшмәләрнең, белем бирү оешмалары, дәүләт күзәтчелек органнары, башка оешма вәкилләре.

## 2. Белем бирү оешмаларының яңа уку елына әзерлеген кабул итүнең максат һәм бурычлары

2.1. Максатлар:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү оешмаларының уку елына әзерлеген бәяләүне оешкан төстә үткәрү;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы һәр белем бирү оешмасының һәм тулы мәгариф системасының ресурслар белән тәэмин итү (оештыру, матди-техник, финанс, социаль) буенча үсешен тоткарлаучы проблемаларны ачыклау.

2.2. Бурычлар:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф оешмаларының яңа уку елына әзерлеген тәэмин итү;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәгариф оешмаларында белем бирү процессын оештыру өчен шартлар тудыру;
- мәгариф оешмаларының дәүләт нормативларын үтәвен тикшереп

тору;

- мәгариф оешмаларының матди-техник базасы торышына мониторинг ясауны тәэмин итү;

- юнәлешләр буенча белешмәләр банкын төзү;

- мәгариф оешмалары эшчәнлеген регламентлый һәм җайга сала торган норматив документлар әзерләү;

матди-техник тәэмин итү;

комплекслы иминлекне тәэмин иту,

- мәгариф оешмаларының укучылар һәм тәрбияләнүчеләр белән тулылануы.

## 3. Кабул итү алгоритмы

3.1. Муниципаль белем бирү оешмаларының яңа уку елына әзерлеген бәяләү турындагы Нигезләмә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының барлык белем бирү оешмаларына җибәрелә.

3.2. Нигезләмә нигезендә белем бирү оешмасында яңа уку елына әзерлек буенча комиссия төзелә, комиссия составы агымдагы елның 23 июненә кадәр белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан раслана.

3.3. Муниципаль белем бирү оешмаларын кабул итү комиссиясе барлык муниципаль белем бирү оешмаларын график нигезендә кабул итә.

3. 4. Кабул итү нәтиҗәсе әзерлек актында чагыла.

3.5. Мәгариф оешмасының әзерлек акты мәгариф оешмасы җитәкчесе тарафыннан бер нөсхәдә рәсмиләштерелә, комиссия җитәкчесе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

3.6. Акт мәгариф оешмасына тапшырыла.

## 4. Кабул итү процедурасы

4.1. Муниципаль бюджет мәгариф оешмаларын кабул итү комиссиясе график буенча мәгариф оешмаларына бара һәм Нигезләмә нигезендә яңа уку елына әзерлекне бәяли.

4.2. Кабул итү барышында уку-укыту оешмасының яңа уку елына әзерлеге критерийлары буенча белем бирү оешмасы комиссиягә өйрәнү өчен документлар тапшыра.

4.3. Комиссия тарафыннан белем бирү оешмасының түбәндәге биналарының әзерлеге кабул ителә:

- уку класслары, төркем бүлмәләре;

- спорт заллары, акт һәм музыка заллары;

- туклану блогы;

- шулай ук белем бирү оешмасының каралтылар һәм спорт корылмалары белән бергә территориясе.

4.4. Белем бирү оешмасы җитәкчесе кабул итү вакытында комиссиягә белем бирү оешмасында белем бирү процессын оештыруны регламентлый торган документлар тапшыра.

4.5. Комиссиянең әзерлек актында кабул итү нәтиҗәләре һәм гомуми нәтиҗә чагылдырыла: БО - «кабул ителде», БО - «кабул ителмәде».

4.5.1. Белем бирү оешмасы түбәндәге очракларда «кабул ителде» дип санала:

- барлык устав документлары булганда;

- белем бирү оешмасы тарафыннан янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлгәндә;

- белем бирү оешмасы тарафыннан белем бирү процессы катнашучылары өчен санитар-эпидемиологик норма таләпләре үтәлгәндә;

- белем бирү процессында катнашучыларның физик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар булганда;

- ФГОС таләпләренә туры китереп, укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең укуы һәм үсеше өчен матди-техник шартлар булганда.

4.5.2. Белем бирү оешмасы түбәндәге очракларда «кабул ителмәде» дип санала:

- янгын куркынычсызлыгы таләпләре, санитар законнар үтәлмәгәнлектән әзерлек актына кул куелмаса;

- оештыру документлары тулы күләмдә тәкъдим ителмәсә;

- спорт залының һәм спорт җиһазларының канәгатьләнмәслек торышы фактлары һәм шартлар бозылулар билгеләнгән булса;

- сыйфатлы туклануны оештыру өчен шартлар булдырылмаса (яки бозылулар билгеләнгән булса).

## 5. Белем бирү оешмасын кабул итү нәтиҗәләре

5.1. Белем бирү оешмасының уку елына әзерлеген бәяләү нәтиҗәләре белем бирү оешмалары җитәкчеләренә җиткерелә.